ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2021. с. Муслюмово 105

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2015 елның 23 ноябрендәге 547 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (25.02.2021 ел редакциясендә)**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Муниципаль функцияләрне башкару (муниципаль хезмәтләр күрсәтү) буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 сентябрендәге 1140 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары һәм Мөслим муниципаль районы Уставы нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген һәм административ регламентларны раслау турында» 2015 елның 23 ноябрендәге 547 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 3 нче кушымтасына кертергә:

1) **2.6 пунктына түбәндәге пунктча өстәргә: «Салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына белешмә (белешмәләр);**

2) **3.4.1 пунктны «законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пеняләр һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар» пунктчасы белән тулыландырырга.**

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген һәм административ регламентларны раслау турында» 2015 елның 23 ноябрендәге 547 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 13 нче кушымтасына кертергә:

**1) 2.8 пунктны «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.» пунктчасы белән тулыландырырга;**

**2) 3.4.1 пунктны «законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар» пунктчасы белән тулыландырырга.**

3. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген һәм административ регламентларны раслау турында» 2015 елның 23 декабрендәге 547 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарындагы 93 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 2.8 пунктны «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.» пунктчасы белән тулыландырырга;**

**2) 3.4.1 пунктны «законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар» пунктчасы белән тулыландырырга.**

4. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**